# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru

## К А Р А Р

07.12.2020 № 595

**2020 елның 6 декабрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе 2020 елның 6 декабрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның нигезендә:

Тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлегенә 3280 катнашучы кертелгән, референдумда тавыш бирүдә катнашучылар саны 2268, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 69,15%ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

2071 (91,31%) референдумда катнашучы “Әйе” позициясе өчен тавыш бирде, бу референдумда тавыш бирүдә катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; “Юк” позициясе өчен 195 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 8,60% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районының территориаль сайлау комиссиясе карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә 2020 елның 6 декабрендә үткәрелгән референдумны узган, референдум нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. “2021 елда Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, балачактан инвалид, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, Чернобыль АЭСы авариясен бетерүдә катнашучылардан тыш, 300 сум сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге | 1.Яңа Кенәр авылында автомобиль юлларын вак таш җәеп тигезләү:<br>- Татарстан ур.;<br>- Киров ур.;<br>- Ямашев ур.;<br>- Комсомол ур.<br>2. Юл полотносының нигезен салу һәм вак таш җәю:<br>Яңа Кенәр – Урак һәм Чүкеч урамына бару юлы – Ленин урамы (150 м)<br>Яңа Ашыт – Вахитов ур. (100 м)<br>Шурабаш - Тынычлык ур. (280 м)<br>- Гагарин ур. (71 м)<br>Шура - Яна Әлиф ур. (200 м)<br>Байкал - Тука ур. (203 м)<br>Яңа Сәрдә - Һ.Такташ ур. (109 м)<br>Сөрде -Совет ур. (100 м)<br>- Киров ур. (214 м)<br>Югары Оры -Киров ур. (196 м)<br>Түбән Оры - Җиңү ур. (50 м)<br>- Г.Гафиятуллин ур. (50 м)<br>- Тукай ур. (148 м)<br>Кызыл-Яр - Нариман ур. (30 м)<br>- Киров ур. (75 м)<br>- Тукай ур. (40 м) |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | 1. Балалар мәйданчыгы сатып алу һәм Яңа Кенәр авылында урнаштыру (1 данә);<br>2. Яңа Кенәр авылы,1 Май урамындагы зиратны киртәләп алу өчен материал сатып алу һәм киртәләү(285 м);<br>1. 3.Яңа Кенәр авылына керү юлына аншлаг (композицияләр) кую. |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә" дигән сорау буенча карар кабул ителде дип табарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырырга, әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л.И. Нурмиева